

Ельник районында татар милләтле эшмәкәрләребез арасында Шәмил Кәрим улы Мещеров унышлы эшләп килә. Ул ООО «За мир» хужалыгы житәкчесе. Шәмил Кәрим улы болай ди: «Мал-туар комплексында хезмәт автоматлаштырылган икән, ул тулысынча автоматизировать ителгән булырга тиеш».
Кvп кенә мал-туар асрый торган комплексларда эшчеләр бер проблема белән яшиләр: техника малларга ашамлык эләшкәннән сон, аларны караучылары корәк тотып, малкайлар житсен дип, каршыларына якынрак елыштырып баралар. Ә замировецлар бу проблеманы чишv юлын тапканнар.      Гади мотоблокка кин корәк ябыштырганнар. Шулай иттереп малга ашны жинелрәк һәм тизрәк елышторалар. Маллар стойлоларынын бер ягыннан эләшеп чыккач, жинел генә икенче яктагы малларга эләшә башлыйлар – тәртип урнаша шулай. Шәмил Кәрим улынын хужалыгында шундый vзләре уйлап тапкан техникада Сергей Викторович Анашкин эшли. «Скотник буларак биредә ул кvптән тvгел эшли башлады,- ди предприятия директоры Ш.К.Мещеров. – Жаваплы һәм тырыш булганга, яхшы яктан vзен кvрсәтте. Хатыны Татьяна Викторовна биредә сыер сава һәм аларга хужалык зур йорт тозеп бирде. Ике балалары белән рәхәтләнеп яшиләр шунда. ООО «За мир» хужалыгында шундый социаль ярдәм алучылар бер алар гына тvгел». Хезмәткә жаваплы якын килеп эшләгәнгә, бер урында басып тормый хужалык; унышлары кvзгә кvренеп шатландыра.